**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Сорочьи Горы һәм Кама поселогы авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

30 ноябрь, 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге LXIII-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 30 ноябрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Сорочьи Горы һәм Кама поселогы авыл торак пунктларының гражданнар җыеннары КАРАР КЫЛДЫ:

– 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Сорочьи Горы һәм Кама поселогы авыл торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм 1 төркем инвалидлардан гайре, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

– Олы Елга, Сорочьи Горы авылларында суэтем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алмаштыру (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга, Сорочьи Горы, Казаклар, Кама поселогы торак пунктларында урам утлары өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Сорочьи Горы авылының Садовая-2 урамында юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташны ташу буенча транспорт хезмәтләре, ташны җәю (түшәү), эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга, Сорочьи Горы, Казаклар, Кама поселогы торак пунктларында урамнарның юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (тору) (кардан чистарту) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

– Олы Елга авылының Нариманов урамындагы Бизнә инеше аша җәяүлеләр күперен ремонтлау (материал сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авылы зиратына илтүче юлның җәяүлеләр күперен ремонтлау (материал сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авылының 1 нче Яңа урамына тышкы суүткәргеч салу (220 см тирәнлектә траншея казу, 63 мм диаметрлы торбалар салу )сузу), задвижка (эшермә), ЖБИ боҗрасы сатып алу һәм урнаштыру, траншеяны күмү;

– Казаклар авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авылында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган обелискны ремонтлау (материал сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам, 16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Садриев